РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕБЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422071, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Кильдебяк, ул. Кооперативная, 20а
тел. (84362) 45-5-50

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КИЛДЕБӘК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

422071, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Килдебәк авылы, Кооперативная урамы, 20а йорт
тел. (84362) 45-5-50

e-mail: Kilb.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

03.03.2025 — №4

Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге башкарма комитетының 04.06.2014 ел, №33 карары белән расланган Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Җир кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 5 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында " 26.12.2024 ел, №485-ФЗ Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Саба муниципаль районының Килдебәк авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибенә, Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге башкарма комитетының 04.06.2014 ел, №33 карары белән расланган «Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.3.3 пунктында «автомобиль юлына бүлеп бирелгән» сүзләреннән соң «беренче, икенче яисә өченче категорияле " сүзләрен өстәргә»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге рәсми сайтында hhttp://saby.tatarstan.ru/kildebiak адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Килдебәк авыл җирлеге башлыгы — Н.Н.Заһидуллин